РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Село Янурусово, улица Ленина, дом 43а, 423370 Телефон 4-10-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
Ленин урамы,43 а йорт, Янурыс авылы, 423370 Телефон: 4-10-19

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000

РЕШЕНИЕ
29 январь 2015 ел

КАРАР
№ 5

## Янурыс авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Янурыс авыл җирлеге Уставының 11,12 ст. нигезендә Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 30 гыйнварындагы № 4» референдум үткәрү инициативасы турында", Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының 2015 елның 30 гыйнварындагы 4 номерлы «референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Янурыс авыл җирлеге Советы хәл итә:

1. 2015 елның 29 мартына Янурыс авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2015 елда Янурыс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан һәм ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, Коралль Көчләр сафларында хезмәт иткән гражданнардан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру;;

-җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;;

- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту);;

- җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм тормышка ашыру;

- көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту

ЮК ӘЙЕ".

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янурыс
авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Мөхәмәдиева